| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ |
| --- | --- |
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | **ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |
| 423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38<br>тел.: (85593) 2-42-05, факс: (85593) 2-80-13 | 423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38<br>тел.: (85593) 2-42-05, факс: (85593) 2-80-13 |


**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 09 » 02 2023 г. №160

2023-2026 елларга Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында конкуренция үсешенә ярдәм итү буенча «юл картасы» чаралар планын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясе субъектларында конкуренция үсеше стандартын раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 05.09.2015 № 1738-р күрсәтмәсе, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр базарларында конкуренцияне үстерү өчен шартлар тудыру максатларында, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. 2023-2026 елларга кушымта итеп бирелгән Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында конкуренция үсешенә ярдәм итү буенча чаралар планын («юл картасын») расларга.

2. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының «2020-2022 елларга Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында конкуренция үсешенә ярдәм итү буенча чаралар планын («юл картасын») раслау турында» 14.03.2022 ел, № 172 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталы составында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Рәсми Татарстан» дәүләт хакимияте

һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм Порталы составында http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе С.П. Самонина

Башк. А.М. Магамедова
ТЕЛ. 2-42-06

Татарстан Республикасы Ютазы
муниципаль районы Башкарма комитеты
___________ ел № ______
карарына

**2023-2026 елларга Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында конкуренция үсешенә ярдәм итү буенча чаралар планы («юл картасы»)**

| № т/б | Мәсьәләне хәл итә торган чара исеме | Җаваплы башкаручылар һәм төп катнашучылар | Чараны гамәлгә ашыру сроклары | Максатчан индикаторлар | Күрсәткеч индикаторын исәпләү методикасы | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|---|
| **Торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре базары** | | | | | | |
| 1 | Торак-коммуналь хуҗалыгы объектларын концессия килешүләре (конкурс процедуралары) нигезендә идарәгә тапшыру | ТР Ютазы муниципаль районының Башкарма комитеты, Ютазы муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы | 2023 - 2026 еллар | Актуальләштерелгән графиклар нигезендә, үткәрелгән идарә нәтиҗәлелегенә анализ нәтиҗәсендә, концессия килешүләре (конкурс процедуралары) нигезендә тапшырылган муниципаль берәмлек торак-коммуналь хуҗалыгы объектлары өлеше:<br><br>2023 елда - 20 %;<br>2024 елда - 30 %;<br>2025 елда - 40 %. ;<br>2026 елда - 50%. | V = A / B x 100%, биредә:<br>A - муниципаль берәмлекнең концессион килешүләр (конкурс процедуралары нигезендә тапшырылган торак-коммуналь хуҗалыгы объектлары саны, берәмлек; B - муниципаль берәмлек торак-коммуналь хуҗалыгы объектларының гомуми саны, берәмлек | |
| **Ваклап сату базары** | | | | | | |
| 1 | Кече һәм ерак авылларда яңа сәүдә объектлары ачу | Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль | 2023 - 2026 еллар | | Абсолют күрсәткеч. Исәп-хисап ясау методикасы таләп ителми | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | районы Башкарма комитеты, авыл җирлекләре Башкарма комитетлары. | | Кече һәм ерак авыл торак пунктларында ачылган сәүдә объектлары саны, берәмлек;<br>2023 елда - 1;<br>2024 елда - 1;<br>2025 елда - 1;<br>2026 елда - 1. | | |
| | | | | | | |
| **Җир өсте транспортында пассажирлар йөртү хезмәтләре базары** | | | | | | |
| 1 | Җайга салына торган тарифлар (шәһәр һәм шәһәр яны хәбәрләрендә) буенча даими муниципаль маршрутларда гражданнарның аерым категорияләре өчен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез файдалану мөмкинлеген тәэмин итү* | Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты | 2023 - 2026 еллар | Җайга салынулы тарифлар буенча даими муниципаль маршрутларда (шәһәр һәм шәһәр яны), җайга салынулы тарифлар буенча даими муниципаль маршрутларда пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы транспорт предприятиеләренең гомуми саныннан (шәһәр һәм шәһәр яны) аерым категория гражданнар өчен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән тигез файдалануны тәэмин итә торган транспорт предприятиеләре өлеше, %:<br><br>2023 елда - 2,3;<br>2024 елда - 2,3;<br>2025 елда - 2,3;<br>2026 елда - 2,3. | V = A / B x 100%, биредә: A - җайга салына торган тарифлар (шәһәр һәм шәһәр яны транспортында), буенча даими муниципаль маршрутларда гражданнарның аерым категорияләре өчен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез файдалану мөмкинлеген тәэмин итә торган транспорт предприятиеләре саны, берәмлек; B - җайга салына торган тарифлар буенча даими муниципаль маршрутларда пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы транспорт предприятиеләренең гомуми саны (шәһәр һәм | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | шәһәр яны транспортында), берәмлек | |
| **Конкурентлык мохитен үстерү буенча системалы чаралар** | | | | | | |
| **Муниципаль милек объектлары белән идарә итү процессларын камилләштерү** | | | | | | |
| 1 | Реклама конструкцияләрен урнаштыру өлкәсендә конкуренцияне үстерү | Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты, инфраструктура үсеше бүлеге | 2023 - 2026 еллар | Реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә шартнамә төзү срогын кимендә 5 елга билгеләү<br><br>2023 елда - 100%;<br>2024 елда - 100%;<br>2025 елда - 100%.<br>2026 елда - 100%. | Абсолют күрсәткеч. Исәп-хисап ясау методикасы таләп ителми | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Лотларны берләштерүне булдырмау<br>(1 лот - 1 реклама конструкциясе)<br><br>2023 елда - 100%;<br>2024 елда - 100%;<br>2025 елда - 100%.<br>2026 елда - 100%. | Абсолют күрсәткеч. Исәп-хисап ясау методикасы таләп ителми | |
| **Дәүләтнеке булмаган (муниципаль булмаган) социаль юнәлешле оешмаларны һәм социаль эшкуарлыкны үстерүгә ярдәм** | | | | | | |
| **1** | Социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмаларга дәүләт ярдәме чаралары турында мәгълүмат | Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты | 2023 - 2026 еллар | 2023 елда - 1;<br>2024 елда - 2;<br>2025 елда - 3;<br>2026 елда - 4. | Абсолют күрсәткеч. Исәп-хисап ясау методикасы таләп ителми | |
| **Кече һәм урта эшкуарлык субъектлары товарларының, эшләренең, хезмәтләренең конкурентлыкка сәләтлелеген үстерү** | | | | | | |
| 1 | 44-ФЗ буенча муниципаль берәмлек сатып алган кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларыннан сатып алулар өлеше | Муниципаль заказчылар, Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының муниципаль заказ буенча секторы | % | 020 елда кече һәм урта эшкуарлык субъектлары һәм социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар гына катнашкан сатып алулар өлешен арттыру -30 %;<br>2022 елда катнашучылары кече һәм урта эшкуарлык субъектлары һәм социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар гына булган социаль сатып алулар өлешен саклап калу 2022 елда-30 %;<br>2023 елда-30 %. | V = A / B x 100%, биредә:<br>A - катнашучылары СМП яисә СОНКО гына булган муниципаль сатып алулар саны , берәмлек;<br>B - муниципаль сатып алуларның гомуми саны, берәмлек. | |
| **«Биржа мәйданчыгы» электрон ресурсы аша сатып алулар гамәлгә ашыручы предприятиеләр санының артуы** | | | | | | |
| **1** | Предприятиеләр тарафыннан «Биржа мәйданчыгы» | Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты | 2023 - 2026 еллар | «Биржа мәйданчыгы» электрон ресурсы системасында субъектларның сатып алуларга | Абсолют күрсәткеч. Исәп-хисап ясау методикасы таләп | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | электрон ресурсы аша кече һәм урта бизнес сатып алуларын тәэмин итү | | | ихтыяҗларын урнаштыру | ителми | |
| **Муниципаль берәмлекне муниципаль / региональ дәрәҗәдә алга җибәрүгә юнәлдерелгән чаралар** | | | | | | |
| 1 | Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының туристлык җәлеп итүчәнлеген үстерү | Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты, Авыл җирлекләре башлыклары | 2023 - 2026 еллар | Элекке елга карата туристлар агымы үсеше,<br>2023 елда - 101%;<br>2024 елда - 102%;<br>2025 елда - 103%;<br>2026 елда - 104%. | | |
| **Медицина хезмәтләре базары** | | | | | | |
| 1 | Шәхси медицина үзәкләре булдыру | Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты | 2023 - 2026 еллар | Шәхси медицина үзәкләре саны:<br>2023 елда - 0;<br>2024 елда - 1;<br>2025 елда - 1;<br>2026 елда - 1. | Абсолют күрсәткеч. Исәп-хисап ясау методикасы таләп ителми | |